РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район, село Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы, Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: Korsab.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
28.10.2024 №7п

Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең
Түбән Утар торак пункты гражданнарының үзара салым
акчаларыннан файдалану турында җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. 2024 елның 11 ноябрендә 15.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Түбән Утар торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Саба районы, Түбән Утар авылы, Киров урамы, 1а йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Түбән Утар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Утар торак пунктында җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын ремонтлау - грунт эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны "Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.Р. Гыймадиев